МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.11.2023 Казан ш № 856

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20.06.2019 №484, 16.08.2019 №624, 14.11.2019 №1023, 18.06.2020 №436, 27.07.2020 №536, 24.09.2020 №669, 18.12.2020 №876, 02.06.2021 №388, 20.09.2021 №670, 15.11.2021 №837, 28.02.2022 №134, 19.04.2023 №298, 08.09.2023 №726 боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2023 елның
1 ноябрендәге 856 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ буларак тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәреш

Регламентның 4 нче кушымтасында «*» астөшермәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*» – документның төре һәм эчтәлеге граждан социаль хезмәтләрдән файдаланырга теләгән социаль хезмәт күрсәтүне оештыру төренә (аның структур бүлекчәсенә) бәйле:

мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләре, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләре, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексны үзәкләренең социаль-теркнәкләндерү бүлекчәләре өчен – социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ кешенең сәламәтлеге турында медицина бәяләмәсе (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау территориаль органына күрсәтү өчен);

халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренең бүлекчәләре (төркемнәре) өчен – гражданинның когнитив яки интеллектуаль бозылулары, аутизм спектры бозылулары булуы турында мәгълүмат;

халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең наркомания белән авыручыларны социаль тернәкләндерү бүлекчәләре өчен – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Стационар шартларда, көндезге стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында кулланыла торган медицина документларының унификацияләнгән формаларын һәм аларны алып бару тәртибен раслау турында» 2022 елның 05 августындагы 530н номерлы боерыгы белән расланган форма буенча өземтә итеп бирелгән эпикриз».

Социаль хезмәтләр күрсәтүгә гариза биргән гражданнар өчен бирелми:

халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлекчәләрендә;

сукырларны һәм начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү үзәгендә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023-2026 елларда «Аутизм спектры бозылулары һәм башка психик тайпылышлары булган инвалидларны эшкә урнашкан вакытта эшкә урнашуда һәм озата йөрүдә булышлык күрсәтеп торуны оештыру» сынау проектын гамәлгә ашыру турында» 2023 елның 19 июнендәге 727 номерлы карары нигезендә аутизм спектры бозылулары һәм башка психик тайпылышлары булган инвалидларны эшкә урнаштыру буенча сынау проектында катнашу өчен.».